**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 февраль № 99

г. Казань

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы (алга таба – Конкурс) турындагы нигезләмәне;

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын.

2. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты» дәүләт бюджет учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Конкурс үткәрүне оештыруны;

Конкурс комиссиясе карары нигезендә Конкурста җиңүчеләр дип танылган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар белән аларның устав эшчәнлеге нигезендә файдалану өчен иң күбе ике елга Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, 8 март урамы, 18 нче йорт, литер В адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән законнар нигезендә бушлай файдалану турында шартнамәләр төзүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\99.doc

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

**Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсында катнашу турында гариза**

| | |
|---|---|
| Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың тулы исеме | |
| Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың кыскартылган исеме | |
| Дәүләт теркәвенә алу датасы (төзегәндә); Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына төзү турында язу кертү датасы | |
| Төп дәүләт теркәү номеры | |
| ИНН | |
| КПП | |
| Даими эшләүче органның адресы (урнашкан урыны) | |
| Почта адресы | |
| Элемтә өчен телефон номеры | |
| Электрон почта адресы | |
| «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайты адресы | |
| Җитәкченең вазыйфасы исеме | |
| Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | |

| | |
|---|---|
| Соңгы өч ел эчендә гамәлгә кую документлары нигезендә оешма гамәлгә ашырган «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган эшчәнлек төрләре турында, шулай ук мондый эшчәнлекнең эчтәлеге һәм нәтиҗәләре хакында мәгълүматлар (эшчәнлек төрләре, тормышка ашырылган программаларның, проектларның, чараларның эчтәлекләре һәм тәгаен нәтиҗәләренең кыскача тасвирламасы) | |
| Соңгы өч ел эчендә гамәлгә кую документлары нигезендә оешма «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга максатчан билгеләнештә файдаланган акча күләме турында мәгълүматлар<br>(һәр ел өчен: акчаның гомуми күләме, гражданнардан максатчан керемнәр күләме, Россия оешмаларыннан максатчан керемнәр күләме, чит ил гражданнарыннан һәм гражданлыгы булмаган затлардан максатчан керемнәр күләме, чит ил оешмаларыннан максатчан керемнәр күләме, коммерциягә карамаган оешмаларның максатчан капиталыннан керемнәр күләме, реализацияләнгәннән тыш керемнәр күләме, товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр реализацияләүдән керемнәр күләме) | |
| Соңгы өч елда федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән коммерциягә карамаган хөкүмәтнеке булмаган оешмалар конкурслар нәтиҗәләре | |

| | |
|---|---|
| буенча коммерциягә карамаган оешмага бүлеп биргән грантлар турында мәгълүматлар (күрсәтелгән оешмаларның исеме, грантларның күләмнәре, аларны алу датасы, тормышка ашыру өчен алар бүлеп бирелгән проектларның (чараларның) кыскача тасвирламасы) | |
| Соңгы өч елда федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан һәм җирле бюджетлардан коммерциягә карамаган оешма алган субсидияләр турында мәгълүматлар (субсидияләр бирү турында карарлар кабул иткән органнар исеме, субсидияләр күләме, аларны алу даталары, тормышка ашыру өчен алар бирелгән чараларның (программаларның, проектларның) кыскача тасвирламасы) | |
| Коммерциягә карамаган оешманың ассоциацияләрдә, берлекләрдә, коммерциягә карамаган партнерлыкларда һәм әгъзалыкка нигезләнгән башка коммерциягә карамаган оешмаларда (шул исәптән чит илләрнекендә) әгъза булып торуы турында мәгълүматлар (мондый оешмаларның исеме һәм аларда әгъза булып тору вакытлары) | |
| Коммерциягә карамаган оешманың хезмәткәрләре саны | |
| Коммерциягә карамаган оешманың ихтыярый затлары саны | |
| Коммерциягә карамаган оешманың милек хокукындагы күчемсез мөлкәте турында мәгълүматлар (исеме, мәйданы, кадастр саннары, адреслары, милек хокукын дәүләт теркәвенә алу датасы) | |

| | |
|---|---|
| Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың узган календарь ел өчен теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга һәм (яки) бюджеттан тыш дәүләт фондларына исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу турында мәгълүматлар | |
| Коммерциягә карамаган оешма гамәлгә ашыру өчен объекттан файдаланырга йөкләмә ала торган «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган эшчәнлекнең төрләре турында мәгълүматлар | |
| Коммерциягә карамаган оешманың мөлкәтне бушлай файдалануга бирүгә булган ихтыяҗын нигезләү | |
| Объекттан бушлай файдалану турында бертип форма буенча шартнамә төзүгә ризалык | |
| Теркәлә торган документлар исемлеге | |

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсында катнашуга гариза составында кертелгән мәгълүматның (шул исәптән документларның) дөреслеген раслыйм.

Конкурс шартлары белән таныштыс һәм алардан риза.

| ______________________ | ______________ | ______________ |
|---|---|---|
| (коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең вазыйфасы исеме) | (имзасы) | (Фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

20___ ел «___» __________ М.У.

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Гаризаларны бәяләү критерийлары**

| Т/с | Бәяләү критерийлары | Иң күп балл | Баллар кую |
|---|---|---|---|
| «Соңгы өч елда социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманы карап тоту һәм аның эшчәнлеге нәтиҗәләре» критерие буенча | | | |
| 1. | Оешманы дәүләт теркәвенә алган (төзегәндә) көннән үткән тулы еллар саны | 5 | Күрсәткеченең мәгънәсе иң югары булган гаризага тиешле күрсәткеч өчен иң зур булган балл куела, калган гаризаларга аларда күрсәтелгән күрсәткеч мәгънәләренең күрсәткечнең бу күрсәткеч өчен иң зур баллга тапкырланган иң югары мәгънәсенә чагыштырмасына тигез булган баллар саны куела, ул бер баллга кадәр түгәрәкләнә. Моның белән бергә, күрсәткечнең мәгънәсе нульгә тигез булса, гаризага теләсә кайсы очракта да тиешле күрсәткеч буенча нуль куела. |
| 2. | Соңгы өч елда оешма эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланган акчаның уртача еллык күләме | 6 | |
| 3. | Соңгы өч елда оешма федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән хөкүмәтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмалардан конкурс нәтиҗәләре буенча алган грантлар күләме | 4 | |
| 4. | Соңгы өч елда оешма федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан һәм җирле бюджетлардан алган субсидияләр күләме | 4 | |
| 5. | Соңгы өч елда оешма эшчәнлеге нәтиҗәләренең социаль әһәмияте, тәгаенләнгән булуы, үлчәп булырлыгы, релевантлыгы (оешма эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге) | 15 | Бәяләү һәм гаризаларны чагыштыру нәтиҗәләре буенча һәр гаризага комиссия 0 дән 15 кә кадәр балл куя (эксперт бәясе) |
| 6. | Соңгы ел елда оешма эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылган акча күләме белән мондый эшчәнлекнең нәтиҗәләре чагыштырмасы (оешма эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге) | 10 | Бәяләү һәм гаризаларны чагыштыру нәтиҗәләре буенча һәр гаризага комиссия 0 дән 10 га кадәр балл куя (эксперт бәясе) |

| «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың торак булмаган урынны бушлай файдалануга бирүгә булган ихтыяҗы» (торак булмаган урыннар биргәндә) критерие буенча | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Оешма эшчәнлегенең эчтәлеге һәм аның гамәлгә ашыру өчен мөлкәт таләп ителә торган эшчәнлеге төрләренә туры килүе | 10 | Бәяләү һәм гаризаларны чагыштыру нәтиҗәләре буенча һәр гаризага комиссия 0 дән 10 га кадәр балл куя (эксперт бәясе) |
| 8. | Оешманың мөлкәтне бушлай файдалануга бирүгә булган ихтыяҗы нигезле булу-булмау | 10 | Бәяләү һәм гаризаларны чагыштыру нәтиҗәләре буенча һәр гаризага комиссия 0 дән 10 га кадәр балл куя (эксперт бәясе) |

F:\KARAR\2015\99-1.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 18 февраль, 99 нчы
карары белән расланды

**Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы үткәрү буенча конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Фомин Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе – комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Сафина Зөлфия Нурмөхәммәт кызы | «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе – комиссия рәисе урынбасары |
| Насыйров Рөстәм Равил улы | «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары – комиссия сәркатибе |
| Беляков Роман Юрьевич | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданнар җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Альмукова Инна Наил кызы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт мөлкәтеннән файдалану бүлеге башлыгы |
| Алексеева Татьяна Георгиевна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт программаларын һәм проектларын тормышка ашыру бүлеге башлыгы |
| Вәлиуллин Дамир Фәргать улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының экологик белем бирү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы |
| Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Забегина Татьяна Вениаминовна | Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Игнатьев Сергей Константинович | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең коммерциягә карамаган оешмалар эшләре буенча баш белгече - эксперты (килешү буенча) |
| Куриленко Лариса Валентиновна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсенең дәвалау ярдәме бүлеге төп консультанты |
| Леонтьева Татьяна Ивановна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләре буенча эшче төркем җитәкчесе, «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Масленникова Оксана Анатольевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының иҗтимагый оешмалар белән эшләү бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| Пелевин Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Фаразлау һәм стратегик үсеш идарәсе башлыгы |
| Тимуца Ольга Вадимовна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының социаль сәясәт мәсьәләләре комиссиясе рәисе урынбасары, «Ретта синдромлы авыруларга булышлык күрсәтү ассоциациясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы директоры, «Окно в НАДЕЖДУ» хәйрия фондын гамәлгә куючы, аның Попечительләр советы әгъзасы, проектларын яраштыручы (килешү буенча) |
| Усанов Владислав Викторович | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары белән эшләү бүлеге башлыгы. |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 18 февраль, 99 нчы
карары белән расланды

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга
мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә түләүсез социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Конкурс «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны (алга таба – мөлкәти ярдәм алучылар) алар белән «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты» дәүләт учреждениесе (алга таба – Иҗтимагый палата аппараты) арасында мөлкәттән бушлай файдалану турында шартнамәләр төзү өчен сайлап алу максатында үткәрелә.

## 2. Конкурс комиссиясе

2.1. Конкурста катнашучыларның гаризаларын карау, аларны бәяләү һәм Конкурска йомгаклар ясау өчен Конкурсны үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – Конкурс комиссиясе) төзелә. Конкурс комиссиясе составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2.2. Конкурс комиссиясе составына Иҗтимагый палата аппараты, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган эшчәнлек юнәлешләре буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Аппараты (килешү буенча) һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) вәкилләре кертелә.

2.3. Конкурс комиссиясе әгъзалары саны тугыз кешедән дә ким булмаска тиеш.

2.4. Конкурс комиссиясе рәисе Конкурс комиссиясе утырышлары үткәрү урынын, датасын һәм вакытын билгели, Конкурс комиссиясе утырышларында

рәислек итә һәм Конкурс комиссиясе сәркатибенә Конкурс комиссиясе эшчәнлегеn оештыру-техник яктан тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшләр куша.

Конкурс комиссиясе рәисе урында булмаса, аның вәкаләтләрен Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

2.5. Иҗтимагый палата аппараты Конкурс комиссиясе әгъзаларына комиссия утырышларын үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында аларны үткәрүгә биш календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр итә, Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне һәм аның утырышлары беркетмәләрен алып баруны гамәлгә ашыра.

2.6. Конкурс комиссиясе, әгәр комиссия утырышында аның әгъзалары гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, бу Нигезләмәдә күздә тотылган үз функцияләрен гамәлгә ашырырга хокуклы.

Конкурс комиссиясе әгъзалары комиссия утырышларында шәхсән катнаша.

Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы комиссия әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булса, утырышта рәислек итүченең тавышы хәл иткеч була.

Конкурс комиссиясе карарлары тиешле утырыш үткән көннән унбиш календарь көн эчендә комиссия утырышында катнашкан комиссия әгъзалары кул куя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Конкурс комиссиясе беркетмәсендә аның әгъзаларының аерым фикере (булганда) күрсәтелә.

2.7. Конкурс комиссиясе әгъзасы шәхсән, турыдан-туры яки читләтеп социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмага объектны бушлай файдалануга бирү белән кызыксынган очракта, ул мөлкәтне бирү турындагы гаризаларны карарга керешкәнче комиссиягә бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Бу вакытта Конкурс комиссиясенең мондый әгъзасы тавышы Конкурс комиссиясе утырышларының хокуклы булуын билгеләгәндә һәм карарлар кабул иткәндә исәпкә алынмый.

Бу Нигезләмә максатлары өчен комиссия әгъзасының шәхси кызыксынуын аның акчалата йә натураль рәвештә керемнәр (нигезсез баю), турыдан-туры комиссия әгъзасы, аның якын туганнары, шулай ук комиссия әгъзасы финанс йөкләмәләре белән бәйләнгән гражданнар яки оешмалар өчен матди файда рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге дип аңларга кирәк.

## 3. Конкурсны үткәрү

3.1. Иҗтимагый палата аппараты Конкурс комиссиясенә үзе социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм сыйфатында файдалана торган мөлкәт (алга таба – мөлкәт) турында мөлкәт ул бушауга карап хәбәр итүне гамәлгә ашыра.

3.2. Иҗтимагый палата аппараты гаризалар кабул итә башларга кимендә ун календарь көн кала «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://oprt/tatarstan.ru сайтында (алга таба - рәсми сайт) Конкурс үткәрү турында хәбәрнамә урнаштыра. Өстәмә рәвештә хәбәрнамә теләсә кайсы массакүләм мәгълүмат чарасында бастырып чыгарылырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге башка сайтларда урнаштырылырга мөмкин.

3.3. Конкурс үткәрү турында хәбәрнамә түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

1) гаризалар кабул итүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органның исемен, урнашкан урынын, почта адресын, электрон почта адресын һәм элемтә өчен телефон номерын;

2) мөлкәт турындагы мәгълүматларны;

3) бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә Конкурста катнашу өчен гаризалар бирү формасын;

4) Конкурста катнашуга гаризалар кабул итү вакытларын (кабул итү вакытлары башлау һәм кабул итеп бетерү датасын һәм вакытын);

5) Конкурста катнашучыларның гаризалары салынган конвертларны ачу урынын, датасын һәм вакытын;

6) Конкурста катнашучыларның гаризаларын карау һәм Конкурска йомгак ясау вакытларын;

7) мөлкәттән бушлай файдалану турындагы шартнамәнең үрнәк формасын.

3.4. Конкурста катнашу өчен күрсәтелгән оешма гариза биргәнгә кадәр кимендә бер ел вакыт эчендә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә кую документлары нигезендә «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган бер яки берничә төр буенча эшчәнлек гамәлгә ашырылса, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) Конкурста катнашучылар була ала,

3.5. Конкурс үткәрү турындагы хәбәрнамә нигезендә Конкурста катнашучылар бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча түбәндәгеләрне үз эченә алган гариза (алга таба – гариза) кертә:

1) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың тулы һәм кыскартылган исемен, аны дәүләт теркәвенә алу датасын (төзегәндә), төп дәүләт теркәү номерын, салым түләүченең тәңгәлләштерелгән тәртип санын, даими эшләүче органның адресын (урнашкан урынын);

2) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың почта адресын, элемтә өчен телефон номерын, электрон почта адресын, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайты адресын;

3) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе вазыйфасы атамасын, фамилиясен, исемен, атасының исемен;

4) гамәлгә кую документлары нигезендә соңгы өч ел эчендә оешма гамәлгә ашырган «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган эшчәнлек төрләре турында, шулай ук мондый эшчәнлекнең эчтәлеге һәм нәтиҗәләре хакында мәгълүматлар (эшчәнлек төрләре, тормышка ашырылган программаларның, проектларның, чараларның эчтәлекләре һәм тәгаен нәтиҗәләренең кыскача тасвирламасы);

5) соңгы өч ел эчендә гамәлгә кую документлары нигезендә оешма «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларда күздә тотылган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга максатчан билгеләнештә файдаланган акча

күләме турында мәгълүматлар (һәр ел өчен: акчаның гомуми күләме, гражданнардан максатчан керемнәр күләме, Россия оешмаларыннан максатчан керемнәр күләме, чит ил гражданнарыннан һәм гражданлыгы булмаган затлардан максатчан керемнәр күләме, чит ил оешмаларыннан максатчан керемнәр күләме, коммерциягә карамаган оешмаларның максатчан капиталыннан керемнәр күләме, реализацияләнгәннән тыш керемнәр күләме, товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр реализацияләүдән керемнәр күләме);

6) соңгы өч елда федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән хөкүмәтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмалар конкурслар нәтиҗәләре буенча коммерциягә карамаган оешмага бүлеп биргән грантлар турында мәгълүматлар (күрсәтелгән оешмаларның исеме, грантларның күләмнәре, аларны алу датасы, тормышка ашырылуы өчен алар бүлеп бирелгән проектларның (чараларның) кыскача тасвирламасы);

7) соңгы өч елда федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан һәм җирле бюджетлардан коммерциягә карамаган оешма алган субсидияләр турында мәгълүматлар (субсидияләр бирү турында карарлар кабул иткән органнар исеме, субсидияләр күләме, аларны алу даталары, тормышка ашырылуы өчен алар бирелгән чараларның (программаларның, проектларның) кыскача тасвирламасы);

8) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың ассоциацияләрдә, берлекләрдә, коммерциягә карамаган партнерлыкларда һәм әгъзалыкка нигезләнгән башка коммерциягә карамаган оешмаларда (шул исәптән чит илләрнекендә) әгъза булып торуы турында мәгълүматлар (мондый оешмаларның исеме һәм аларда әгъза булып тору вакытлары);

9) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың хезмәткәрләре саны турында мәгълүматлар;

10) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың ихтыярый затлары саны турында мәгълүматлар;

11) соңгы өч ел эчендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма милкендәге һәм милкендә элек булган һәм (яки) аның файдалануындагы күчемсез мөлкәт турында мәгълүматлар;

12) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың узган календарь ел өчен теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга һәм (яки) бюджеттан тыш дәүләт фондларына исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу турында мәгълүматлар;

13) коммерциягә карамаган оешма гамәлгә ашыру өчен объекттан файдаланырга йөкләмә ала торган «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 нче һәм 2 нче пунктларында күздә тотылган эшчәнлек төрләре турында мәгълүматлар;

14) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың мөлкәтне бушлай файдалануга бирүгә булган ихтыяҗын нигезләү;

15) конкурс үткәрү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән үрнәк форма буенча мөлкәттән бушлай файдалану турында шартнамә төзүгә ризалык;

16) гаризага теркәлә торган документлар исемлеге.

3.6. Гаризага түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

1) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документларының коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты кул куйган һәм мөһер белән таныкланган күчермәләре;

2) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документ (аны билгеләп кую турында яки сайлау хакында), ә гаризага социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма вәкиле кул куйса, тиешле гамәлләрне кылуга әлеге оешма җитәкчесе кул куйган ышанычнамә яки мондый ышанычнамәнең нотариатта таныкланган күчермәсе;

3) рәсми сайтта урнаштырылган хәбәрнамәдә күрсәтелгән шартнамә формасы буенча алыш-биреш ясау турында яки аны хуплау хакында карар, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документлары белән мондый карар кабул итү каралган булса;

4) соңгы өч елда коммерциягә карамаган оешманың хисап исәбе буенча акча әйләнеше турында мәгълүматлар;

5) коммерциягә карамаган оешма «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 32 статьясындагы 3 нче пункт һәм (яки) 3.1 нче пункт нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларны теркәү өлкәсендәге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына керткән документларның күчермәләре;

6) дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, коммерция һәм коммерциягә карамаган оешмаларның һәм (яки) гражданнар һәм аларның берләшмәләренең социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма эшчәнлегенә биргән бәяне (фикерләрне, тәкъдимнамәләрне) үз эченә алган хатлары яки аларның күчермәләре;

7) Конкурста катнашучының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

3.7. Конкурста катнашуга гаризалар кабул итү Конкурс үткәрү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән гаризалар кабул итә башлый торган көннән егерме календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.8. Бер социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма Конкурста катнашуга бер генә гариза бирергә хокуклы.

3.9. Гариза текстының электрон чыганактагы күчермәсе белән бергә язма рәвештә «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың мөлкәт бирүгә гаризасы» дип язылган ябык конвертта тапшырыла.

Гариза социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма исеменнән эш итәргә хокуклы зат тарафыннан ышанычнамәсез яки социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма вәкиле тарафыннан ышанычнамә нигезендә имзалана.

3.10. Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма гаризаны кабул итү вакыты тәмамланганга кадәр гаризаны үзгәртергә яки кире алырга һәм (яки) аңа өстәп документлар кертергә хокуклы.

## 4. Конвертларны ачу тәртибе

4.1. Конкурс комиссиясе рәсми сайтта урнаштырылган Конкурс үткәрү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән урында, көндә һәм вакытта гаризалар салынган конвертларны халык алдында бер үк вакытта ача.

4.2. Бер социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың Конкурста катнашуга ике һәм аннан да күбрәк гариза биргәнлеге ачыкланган очракта (мондый оешма элек биргән гаризаларын кире алмаган булса), аның барлык гаризалары да каралмый.

4.3. Гаризалар биргән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре конвертларны ачуда катнашырга хокуклы.

4.4. Конвертларны ачканда гаризасы салынган конверты ачыла торган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың исеме игълан ителә, бу Нигезләмәнең 3.5 нче пунктында каралган мәгълүматлар һәм документлар булу турында мәгълүмат конвертларны ачу беркермәсенә кертелә.

4.5. Гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланганнан соң бер генә гариза да кертелмәсә, Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә тиешле мәгълүмат кертелә.

4.6. Гариза биргән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар турындагы, бу Нигезләмәнең 3.5 нче пунктында күздә тотылган мәгълүматлар һәм документлар булу хакындагы мәгълүмат конвертларны ачу процессында рәсми сайтта урнаштырыла.

4.7. Конвертларны ачу беркетмәсе (Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе) Конкурс комиссиясе тарафыннан алып барыла һәм конвертларны ачканнан соң Конкурс комиссиясенең анда катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан турыдан-туры имзалана. Әлеге беркетмә беркетмәгә кул куелган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча Иҗтимагый палата аппараты тарафыннан рәсми сайтта урнаштырыла.

4.8. Гаризалар кабул итү вакыты чыкканнан соң, Иҗтимагый палата аппараты кергән гаризалар белән конвертларны ача (конвертта социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың почта адресы күрсәтелмәгән очракта) һәм аларны алган көннән ун календарь көн эчендә Иҗтимагый палата аппараты аларны җибәргән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмага кире кайтара.

4.9. Гаризаларны кабул итү вакыты дәвамында бер генә гариза да кертелмәсә, Иҗтимагый палата аппараты бу Нигезләмәнең 3.2 нче пункты нигезендә гаризаларны кабул итү тәмамланган көннән иң күбе утыз календарь көн эчендә яңа хәбәрнамә урнаштыра.

## 5. Гаризаларны карау тәртибе

5.1. Конкурс комиссиясе гаризалар кабул ителә торган вакыт эчендә Иҗтимагый палата аппаратына кергән гаризаларны һәм аларга теркәлә торган документларның бу Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен һәм аларны керткән затларның бу Нигезләмәдә билгеләнгән шартларга туры килү-килмәвен тикшерә. Әлеге тикшерүнең вакыты конвертларны ачкан көннән унбиш календарь көннән дә артмаска тиеш.

5.2. Гаризалар кабул ителә торган вакыты эчендә Иҗтимагый палата аппаратына кергән гариза түбәндәге очракларда алга таба карауга тәкъдим ителми, әгәр:

гаризаны түбәндәгеләр кертсә:

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән коммерциягә карамаган оешма булмаган зат;

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 2 статьясындагы 2.1 нче пункт нигезендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма дип танылмаган коммерциягә карамаган оешма;

дәүләт учреждениесе яки муниципаль учреждение булып торучы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма;

бу Нигезләмәнең 3.4 нче пунктында күздә тотылган таләпләргә туры килми торган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма;

гаризада алдан ук ялган мәгълүматлар булса;

гаризага кул куелмаган булса яки аңа тиешле вәкаләтләре булмаган зат тарафыннан кул куелса;

гариза биргән социаль юнәлешле комммерциягә карамаган оешманың теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга һәм (яки) бюджеттан тыш дәүләт фондларына исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булса, мондый оешма бу бурычлары булуга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирмәсә;

гариза биргән социаль юнәлешле комммерциягә карамаган оешманы бетерү турында карар һәм (яки) арбитраж судның мондый оешманы банкрот дип тану һәм конкурс эшен ачу хакындагы карары булса;

гариза биргән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма «Җинаять кылу юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (законлаштыруга) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында» 2001 ел, 7 август, ФЗ-115 нче Федераль законның 6 статьясындагы 2 нче пункт нигезендә төзелә торган оешмалар исемлегенә кертелсә.

5.3. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, бу Нигезләмәнең 5.1 нче һәм 5.2 нче пунктларына таянып, Конкурс комиссиясе гаризаны алга таба карау өчен тәкъдим итү турында яки алга таба карауга тәкъдим итүдән баш тарту хакында карар кабул итә, ул беркетмә белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән беркетмә Конкурс комиссиясе тарафыннан алып барыла, тикшерү төгәлләнгән көндә катнашкан барлык әгъзалар тарафыннан турыдан-туры имзалана һәм беркетмәгә кул куелган көннән соң килүче беренче эш көненнән дә соңга калмыйча Иҗтимагый палата аппараты тарафыннан рәсми сайтта урнаштырыла.

Күрсәтелгән беркетмә, бу Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында күздә тотылган карау өчен тәкъдим итүдән баш тарту нигезләрен күрсәтеп, гаризалары алга таба карау өчен тәкъдим ителмәгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның исемнәрен, гаризалары алга таба карау өчен тәкъдим ителгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар исемнәрен үз эченә алырга тиеш.

5.4. Конкурс комиссиясе гаризалар кабул итә торган вакыт эчендә Иҗтимагый палата аппаратына кергән барлык гаризаларны да алга таба карау өчен тәкъдим итүдән баш тарту турында карар кабул итсә, Иҗтимагый палата аппараты мондый карар рәсмиләштерелгән беркетмәгә кул куйган көннән иң күбе 30 календарь көн эчендә бу Нигезләмәнең 3.2 нче пункты нигезендә яңа хәбәрнамә урнаштыра.

5.5. Конкурс комиссиясе гаризалар кабул итә торган вакыт эчендә Иҗтимагый палата аппаратына кергән бары тик бер генә гаризаны алга таба карау өчен тәкъдим

итү турында карар кабул итсә, Конкурс комиссиясе гариза биргән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманы мөлкәти ярдәм алучы дип билгеләү турында шул ук көндә карар кабул итә. Мөлкәти ярдәм алучыны билгеләү турындагы күрсәтелгән карар тикшерү тәмамланган көндә Конкурс комиссиясенең катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан турыдан-туры имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм беркетмәгә кул куелган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча Иҗтимагый палата аппараты тарафыннан рәсми сайтта урнаштырыла.

5.6. Әгәр дә Конкурс комиссиясе гаризалар кабул итә торган вакыт эчендә Иҗтимагый палата аппаратына кергән ике яки аннан да күбрәк гаризаны алга таба карау өчен тәкъдим итү турында карар кабул итсә, Конкурс комиссиясе мондый карар рәсмиләштерелгән беркетмәгә кул куйган көннән иң күбе 15 календарь көн эчендә әлеге гаризаларны бәяләүне һәм чагыштыруны (алга таба – гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру) гамәлгә ашыра.

5.7. Мөлкәти ярдәм алучыларны билгеләү өчен гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:

1) гариза биргән көнгә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма эшчәнлегенең эчтәлеге һәм нәтиҗәләре;

2) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың мөлкәтне бушлай файдалануга бирүгә булган ихтыяҗы.

Гаризаларны бәяләү, бу Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтага таянып, Конкурста катнашуга гаризаны бәяләү критерийлары буенча Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.8. Гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

1) бу Нигезләмәнең 5.7 нче пунктындагы 1 нче пунктчада күздә тотылган критерий буенча, баллар саны бу Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән 1 – 6 нчы күрсәткечләр буенча Конкурс комиссиясе биргән балларны кушу юлы белән билгеләнә;

2) бу Нигезләмәнең 5.7 нче пунктындагы 2 нче пунктчада күздә тотылган критерий буенча, баллар саны бу Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән 1 – 6 нчы күрсәткечләр буенча Конкурс комиссиясе биргән балларны кушу юлы белән билгеләнә;

3) һәр гариза өчен бу пунктның 1 нче һәм 2 нче пунктчалары нигезендә бирелгән баллар саны бергә кушыла һәм алынган мәгънә гаризаның рейтингын төзи.

5.9. Гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру нәтиҗәләре нигезендә аларның һәркайсына, бу Нигезләмәнең 5.8 нче пунктына таянып билгеләнгән рейтингның йомгаклау мәгънәсе кимүгә карап, тәртип саны бирелә. Рейтингының йомгаклау мәгънәсе иң югары булган гаризага беренче тәртип саны куела. Берничә гаризаның рейтингы бер үк төрле йомгаклау мәгънәсенә ия булса, иң түбән тәртип саны рейтингларының йомгаклау мәгънәләре бер үк төрле булган башка социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалардан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә соңрак теркәлгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма биргән гаризага куела.

5.10. Конкурс комиссиясе гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсен алып бара, анда бәяләү һәм чагыштыру үткәрү урыны, датасы, вакыты турындагы; аларны керткән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның исемнәрен һәм бу Нигезләмәнең 5.7 нче пунктындагы 1 нче һәм 2 нче пунктчалар нигезендә һәр күрсәткеч буенча бирелгән балларны күрсәтеп, гаризалар рейтингының иң чик мәгънәсен билгеләү хакындагы; гаризаларга тәртип саннарын кую турындагы; мөлкәти ярдәмне алучыларны билгеләү хакындагы мәгълүматлар булырга тиеш. Күрсәтелгән беркетмәгә гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру үткәреп бетерелгән көндә анда катнашучы барлык әгъзалар турыдан-туры кул куя, ул беркетмәгә кул куелган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча Иҗтимагый палата аппараты тарафыннан рәсми сайтта урнаштырыла.

5.11. Гаризаларны карау барышында Конкурс комиссиясе Иҗтимагый палата аппараты аша тикшерү үткәрү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, шулай ук башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарыннан соратып ала.

5.12. Конкурс комиссиясе карары нигезендә гаризада күрсәтелгән мәгълүмат буенча аңлатмалар бирү өчен Конкурс комиссиясе утырышына Конкурста катнашуга гариза керткән коммерциягә карамаган оешма вәкилләре чакырылырга мөмкин.

5.13. Гаризалар кабул итә торган вакыт эчендә Иҗтимагый палата аппаратына кергән гаризалар һәм аларга теркәлә торган документлар, Конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләре Иҗтимагый палата аппараты тарафыннан кимендә биш ел саклана.

## 6. Шартнамә төзү

6.1. Конкурс комиссиясенең мөлкәти ярдәм алучыларны билгеләү турындагы карарын рәсмиләштергән беркетмәгә кул куелган көннән 35 календарь көн эчендә Иҗтимагый палата аппараты мөлкәт милекчесе ризалыгы белән Конкурста җиңүчегә (җиңүчеләргә) кул кую өчен мөлкәттән бушлай файдалану турында шартнамә (шартнамәләргә) җибәрә.

Күрсәтелгән шартнамә аны җибәргән көннән 10 календарь көн эчендә мөлкәти ярдәм алучы тарафыннан имзалана һәм Иҗтимагый палата аппаратына кертелә.

6.2. Мөлкәттән түләүсез файдалану турында шартнамә төзү Россия Федерациясе Граждан кодексы һәм башка федераль законнар белән күздә тотылган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6.3. Мөлкәттән бушлай файдалану турында шартнамә төзүдән баш тартылган һәм (яки) Иҗтимагый палата аппараты аны җибәргән көннән 10 календарь көн эчендә мөлкәттән бушлай файдалану турындагы кул куелган шартнамә Иҗтимагый палата аппаратына кертелмәгән очракта, Конкурс комиссиясе мондый баш тарту турында мәгълүмат алган көннән яки мөлкәттән бушлай файдалану шартнамәсен кертү өчен күрсәтелгән вакыт чыккан көннән 15 календарь көн эчендә бу Нигезләмәнең 5.10 нчы пункты нигезендә кабул ителгән мөлкәти ярдәм алучылар

турындагы карарга һәм мөлкәти ярдәм алучы итеп бу Нигезләмәнең 5.9 нчы пункты нигезендә гаризасына аннан соң килүче тәртип саны куелган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманы билгеләү хакындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар кабул итә. Күрсәтелгән карарлар төзелгән көндә Конкурс комиссиясенең катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан кул куела торган беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм беркетмәгә кул куйган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча Иҗтимагый палата аппараты тарафыннан рәсми сайтта урнаштырыла.

## 7. Конкурс комиссиясе карарларына шикаять бирү

Конкурста катнашучылар Конкурс комиссиясе карарларына законнар нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

---